КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 22 май г.Казань № 730

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 4 июль, 512 нче карары белән расланган Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең тармак белгечләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең тармак белгечләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 4 июль, 512 нче карары белән расланган Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең тармак белгечләренең хезмәт хакын арттыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка «, аны Татарстан Республикасы буенча уртача хезмәт хакы дәрәҗәсенә кадәр ирештереп» сүзләрен өстәргә;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Хисап кварталына (S) муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S=\sum_{j=1}^{n}\left(Z_j^p - Z_j^f\right) \times C_j \times m \times (1 + k),$$

монда:

$Z_j^p$ – Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Оешмаларда, индивидуаль эшкуарларда һәм физик затларда ялланып эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакын (хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемне) исәпләү методикасын раслау турында» 2016 елның 14 апрелендәге 188 номерлы боерыгы белән расланган Оешмаларда, индивидуаль эшкуарларда һәм физик затларда ялланып эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакын (хезмәт эшчәнлегеннән уртача айлык керемне) исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә торган план чорына белгечләрнең уртача айлык хезмәт хакының фаразлана торган күләме (агымдагы елның I кварталы, алты ае, тугыз ае, 12 ае);

$Z_j^f$ – Министрлык таләбе буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан шушы гарызнамәдә күрсәтелгән срокларда һәм рәвештә бирелә торган белешмәләр нигезендә исәпләнә торган хисап чорына белгечләрнең уртача айлык хезмәт хакының факттагы күләме;

$C_j$ – белгечләрнең уртача исемлектәге гомуми саны;

m – айлар саны;

k – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасы;

j – белгечләр категорияләре;

n – белгечләр категорияләре саны.»;

13 пунктның алтынчы абзацында «агымдагы елның I кварталында, алты аенда, тугыз аенда, 10 аенда белгечләрнең гомуми уртача исемлек саны» сүзләрен «белгечләрнең гомуми уртача исемлек саны» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе - муниципаль берәмлектә белгечләрнең уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе Татарстан Республикасы буенча уртача хезмәт хакы күрсәткеченә туры килә.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин